*Сәгъдиева Р. К. (КФУ, Казан)*

# ФЕДЕРАЛЬ ИСЕМЛЕККӘ КЕРГӘН ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация:** Ведущая роль в осуществлении задач, связанных с социально- коммуникативной подготовкой школьника к жизни, с развитием речевой культуры, интеллектуальных и творческих способностей принадлежит учебнику как основному средству обучения. В данной статье раскрывается содержание, особенности учебников, представляющие серию учебно-методических комплектов по татарскому языку для образовательных учреждений с русским языком обучения (для изучающих татарский язык как родной).

**Ключевые слова:** учебник, татарский язык, упражнение, правила, метод.

**Features textbooks Tatar language included in the federal list**

**Abstract:** The leading role in the implementation of tasks related to social and communicative preparation of students for life, with the development of speech culture, intellectual and creative abilities belongs to the textbook as the main medium of instruction. This article reveals the contents, especially textbooks, presents a series of teaching kits on the Tatar language for educational institutions with Russian language of instruction (for learners of the Tatar language as the mother tongue).

**Key words:** textbook, Tatar, exercise, rules, method.

2015 нче елда «Мәгариф-Вакыт» нәшрияте бастырган рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар балаларының урта сыйныфлары өчен язылган татар теле дәреслекләре [1, 2, 3, 4, 5] федераль исемлеккә кертелде. 5-7 сыйныфлар 2015-2016 уку елында әлеге дәреслекләр белән укый башлады.

Татар телен укыту программасы үз алдына шактый җитди бурычлар куя:

1. Алдагы сыйныфларда өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау һәм системага салу.

2. Уку-укыту эшен гомумдидактик, лингвистик һәм методик принципларга таянып оештыру.

3. Укучыларның рус мохитендә тәрбияләнүен истә тотып, аларда, беренче чиратта, аралашу компетенциясе булдыру, бу юнәлешне даими рәвештә күз уңында тотып эшләү. Тел күренешләрен аралашу процессында куллана белү укучыларда лингвистик компетенция булдырырга да ярдәм итә.

4. Татар теле дәресләрендә укучыларда лингвокультурологик компетенция булдыру өчен, татар һәм рус халыклары авыз иҗаты әсәрләрен – әкиятләрне, мәкаль-әйтемнәрне, сынамышларны, юрауларны һ.б. активрак куллану.

Укучының белемнәрен системага салу, тирәнәйтү, яңа мәгълүмат бирү, укучыларның сөйләм һәм язу культурасын үстерү, аларны тәрбияләү – татар теле дәресләренең төп максаты. Бу максатка ирешүдә, укытучыларның иң беренче ярдәмчесе – дәреслек. Рус телендә белем бирү оешмаларында укучы татар балалары өчен эшләнгән әлеге дәреслекләр Федераль дәүләт белем стандартлары (ФГОС) таләпләренә җавап бирә.

Теге яки бу дәрәҗәдә таныш теманы өйрәнгәндә, укучыларның белгәннәрен искә төшерүдән башлау яхшырак. Уку мәсьәләсен кую нәкъ менә шуны күздә тотып башкарыла.

Яна материалны да укучыларның элекке белемнәренә таянып аңлату уңай нәтиҗә бирә. Болай эшләү яңа темага җиңелрәк кереп китәргә, аны аңлап үзләштерергә ярдәм итә.

Дәресне проблемалы оештыру, кагыйдәләрне укучыларның үзләреннән чыгарту яки аларны шуңа якын китерү өчен дә дәреслектә материал бар. Грамматик формаларның телдәге кулланылышы да шулай мөстәкыйль күзәтүләр ярдәмендә үзләштерелә. Нәтиҗәләрнең дөреслеген күнегү азагында китерелгән аңлатма яки кагыйдә буенча тикшереп була. Укучыларның

эзләнү һәм акыл эшчәнлеген укытучы тиешле юнәлештә алып барырга гына тиеш.

Дәреслектә билгеле бер күләмдә теоретик материал, күнегүләр, төрле төр иҗади эшләр, материалны кабатлау һәм ныгыту өчен сорау һәм биремнәр, схема һәм таблицалар урын алды. Теоретик белемнәрне үзләштерү һәм аларны ныклы күнекмәгә әверелдерү максатыннан, дәреслектә күнегүләрнең, иҗади эш төрләренең саны шактый арттырылды. Күнегүләр күп булган очракта, алар арасыннан иң кирәклеләрен сайлап, укучыларга тәкъдим итү укытучы карамагына калдырылды. Күнегүләр өчен текстлар мөмкин кадәр оригиналь әсәрләрдән алынды, аларда язучыларның тел үзенчәлекләре тулаем диярек сакланды. Башка дәреслекләрдән аермалы буларак, тәкъдим ителгән дәреслекләрдә күнегүләр өчен аерым микротекстлар тупланды. Һәр дәрестә укучы кыска гына хикәя, шигырь, мәкальәйтемнәр, сынамышлар белән таныша ала. Шул рәвешле укучыда татар язучылары, шагыйрьләре, аларның иҗаты белән танышу, татар халкының авыз иҗаты әсәрләрен истә калдыру мөмкинчелеге булачак. Текстлар, беренчедән, укучыга теге яки бу теоретик мәгълүматны истә калдырырга, ныгытырга ярдәм итсәләр, икенчедән, алар баланы тәрбияләүгә юнәлтелгәннәр. Ягъни һәр дәрестә кулланыла торган текстлар билгеле бер тематика белән бәйләп сайланган. Мәсәлән, бер дәрес өчен алынган текстлар барысы да ата-ананы хөрмәт итү белән бәйле булса, икенче дәрестәге текстлар туган илгә мәхәббәт тәрбияли. Һәр күнегүне башкарганнан соң, укытучы укучыны уйландыра торган, теге яки бу әхлак сыйфатлары белән бәйле сораулар бирергә тиеш. Шул рәвешле укучы бер яктан үзенең, тирә-юньдәгеләрнең холкы турында уйланса, нәтиҗә ясаса, икенче яктан ул татар телендә сөйләшергә мәҗбүр була. Хәзерге көндә рус мохитендә яшәгән, укыган татар баласы үз ана телендә сөйләшә, теләгәнен әйтә белә башлый. Шулай итеп сөйләм күнекмәләрен булдыруга ирешергә мөмкин.

Кагыйдәләр, язма биремнәр, сөйләм үстерү белән бәйле биремнәр, парлап эшләү өчен эш төрләре, өстәмә биремнәр шартлы билгеләр белән күрсәтелде. Укучыларны проект эшләрен башкарырга да җәлеп итәргә мөмкин. Һәр дәреслектә 1-2 проект эше тәкъдим ителә. Дәреслек ахырында орфографик-орфоэпик, синонимнар, антонимнар һәм аңлатмалы сүзлекчәләр бирелде. Шулай ук бәйләнешле

сөйләм үстерү дәресләрендә сочинениеләр язу өчен рус һәм татар рәссамнарының картиналары урнаштырылды.

Дәреслектә тел күренешләренең фәнни яктан дөрес яктыртылуына әһәмият бирелде, теоретик аңлатмаларны җиңеләйтүгә дә игътибар ителде. Укучыларның бирелгән материалны кабул итә алу мөмкинлекләре дә исәпкә алынды.

Укыту процессында дәвамчанлык мәсьәләсе дә зур әһәмияткә ия. Шуны истә тотып, дәреслектә алдагы сыйныфларда өйрәнелгән темалар буенча кыскача гына күзәтү ясала, укучыларның белемнәре искә төшерелә.

Рус һәм татар телләрен өйрәнү нәтиҗәсендә, укучылар телнең аралашу коралы булуына төшенәләр, аны милли мәдәни күренеш буларак аңлыйлар. Туган телне өйрәнү укучы өчен белем алуның төп нигезен тәшкил итә, аны уйлау һәм күзаллауга өйрәтүдә, иҗади мөмкинлекләрен үстерүдә төп чараларның берсе булып тора. Шул ук вакытта укучылар, телдән һәм язма формада аралашу өчен, төрле мәгълүмати мөмкинлекләрдән киңрәк файдалана белергә дә өйрәнәләр. Укучылар телдән һәм язма сөйләмнең дөреслеге кешенең гомуми культурасы үсеше дәрәҗәсен билгеләвен дә аңлыйлар. Алар туган телдәге башлангыч орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерәләр.

Һәр уку елы ахырында укучылар хатасыз яза белүне гомуми үсеш дәрәҗәсенең күрсәткече буларак кабул итә; орфографик һәм орфоэпик кагыйдәләрне, тыныш билгеләрен урынлы куллана белү үз җөмләләрен төзегәндә һәм бирелгән җөмләләрне тикшергәндә кирәк булуына ышана; тел белеменең фонетика, лексикология, сүз ясалышы, морфология һәм синтаксис бүлеге буенча башлангыч мәгълүмат ала; һәр тел материалы алдагы сыйныфларда үтелгән фонетик, лексик, морфологик һәм синтаксик берәмлекләр белән үрелеп бара. Бу исә, үз чиратында, укучыга алга таба катлаулырак төшенчәләр белән эш итүдә таяныч була. Нәтиҗәдә, укучыда танып-белү эшчәнлеге белән кызыксыну барлыкка килә, һәм ул алдагы сыйныфларда татар теле буенча алачак белемнәрнең нигезен тәшкил итәчәк.

Рус телендә белем бирү оешмаларында укучы татар балаларына татар теленнән белем бирүнең төп максаты – Федераль дәүләт стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә татар теленә өйрәткәндә, укучыларда линг-

вистик (тел), коммуникатив (аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәниятлылык) һәм шәхескә кагылышлы компетенцияләр булдыру.

Дәүләт стандартлары таләпләреннән чыгып, ана телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләрне тәшкил итә:

укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;

укучыларның сөйләм эшчәнлеген һәм фикерләү сәләтен, төрле шартларда әдәби телдә дөрес аралаша белү күнекмәләрен үстерү;

татар теле гыйлеме, аның төзелеше, кулланылыш өлкәсе, төп нормалары, сөйләм этикеты, стилистик чаралары белән танышу, сүз байлыгын арттыру;

тел фактларын анализлый, тел күренешләрен күрә, таба белү сәләтен, тәкъдим ителгән мәгълүматтан мөһимен сайлап ала белү осталыгын үстерү;

алынган белемне һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәтү;

дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү;

үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.

«Татар теле» курсын өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ).

Регулятив УУГ (РУУГ):

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;

- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр таба белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;

- максатка ирешү юлларын билгеләү;

- үз эшчәнлегенең максатка ирешүдә ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын күзәтү;

- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

- кагыйдә,күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу ;

- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, үзконтроль;

- биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү;

- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

Танып-белү УУГ (ТБУУГ):

- танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую;

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксы-

нучанлык өлкәсен билгеләве;

- мөстәкыйль рәвештә текстның темасын, күтәрелгән проблеманы ача белү, фикер йөртү;

- уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү;

- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;

- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;

- фикерләүдә логик чылбыр төзү;

- тел берәмлекләренә морфологик анализ ясау күнекмәләре булдыру;

- морфологик берәмлекләрне, төрле чаралардан файдаланып, сөйләм эшчәнлегендә дөрес һәм урынлы файдалана белү;

- телне әдәбият, рәсем һәм музыка сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;

- тел берәмлекләренең әдәби әсәр тудырудагы ролен билгеләү;

- татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү юлы аша телләр арасындагы уртак проблемаларны, уртак кагыйдәләрне, аермалы якларны аерырга өйрәтү;

- сүзлекләрдән, сүзлекчәләрдән, белешмә материаллардан файдалану;

- теге яки бу мәсьәләгә караган фикерне иптәшләренә, укытучыга җиткерү, үз карашыңны дәлилли белергә өйрәтү;

- телне әдәбият, тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру;

- үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.

Коммуникатив УУГ (КУУГ):

- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;

- тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;

- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;

- үз фикерен тормыштагы мисаллар ярдәмендә дәлилли белү;

- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;

- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү,

- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;

- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү;

- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;

- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау, автор фикере белән чагыштыру;

- үз эшен контрольдә тоту,

сыйныфташларына ярдәм итү;

- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга чыгыш ясау;
- иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, күршең белән хезмәттәшлек итү.

Шәхескә кагылышлы УУГ (ШКУУГ):

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар теленә, әдәбиятына һәм башка халыклар теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;
- активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртергә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасы күрсәтү;
- үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау;
- үз уңышларың яки уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру.

Яңа татар теле дәреслекләренең предмет нәтиҗәләре булып түбәндәгеләрне санарга мөмкин:

Танып-белү өлкәсендә:

- фонетик, сүз төзелеше, лексик, морфологик һәм синтаксик берәмлекләр белән эш итүне ныгыту;
- шигъри әсәрләрне сәнгатьле итеп уку;
- мәкальләрнең мәгънәсенә төшенү;
- логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, кечкенә хикәяләр язу;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру;
- сөйләм берәмлекләренең хәрәкәтен тоемлый белү.

Әхлакый кыйммәтләр юнәлеше өлкәсендә:

- татар теленең, әдәбиятының һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен үзара якынайту;
- телнең җәмгыятьтәге ролен ачыклау;
- күнегүләр өчен тупланган текстлар аша укучыны төрле яклап тәрбияләү.

Коммуникатив өлкәдә:

- фонетик, сүз төзелеше, лексик, морфологик һәм синтаксик берәмлекләрне табу, аларны бер-берсеннән аера белү;
- аларның мәгънә һәм төзелеш ягыннан төркемчәләрен билгели алу;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау;
- укыган текстның эчтәлеген сөйли алу, текст белән бәйле сораулар уйлау, сорауларга җавап бирә алу, телдән монолог, диалог төзү, әңгәмә кору;
- бирелгән темага сочинение, сыйныф яки өйгә бирелгән иҗади эшләр, гомуммәдәният темаларына проект эшләре башкару.

Эстетик өлкәдә:

- тел берәмлекләрен сүз сәнгате күренеше буларак аңлау, алар аша әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итү, әдәби әсәрләрдән рухи тәм табу;
- сүзнең эстетик вазифасын, әдәби образлар тудырганда сурәтләү көчен аңлау.

Һәр дәреслеккә укытучылар өчен методик кулланмалар эшләнде. Алар Федераль дәүләт белем стандартлары (ФГОС) таләпләре буенча төзелгән программаны җентекләбрәк аңлату һәм укытучыга дәреслек белән эшләүне җиңеләйтү максатларын күздә тотып төзелде. Ул 2 зур бүлектән тора. Беренче бүлек аңлатма язуын, укытуның көтелгән нәтиҗәләрен, укучыларда формалаштырылырга тиешле универсаль уку-укыту гамәлләрен, эчтәлекнең темаларга һәм сәгатьләргә бүленешен, ел ахырында укучылардан таләп ителгән күнекмәләрне, үтәлергә тиешле язма эшләрнең күләмен, аларны бәяләү нормаларын үз эченә алган эш программасыннан тора. Икенче бүлектә дәрес эшкәртмәләре Федераль дәүләт белем стандартлары (ФГОС) таләбе буенча технологик карталар формасында бирелә. Әлеге дәрес эшкәртмәләре үрнәк буларак китерелә: укытучы эш алымнарын үзенчә үзгәртә, төрләндерә ала. Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре * билгесе белән искәртелде.

Укучылар электрон дәреслек белән дә эшли алачак. Электрон дәреслекләрдән укучы текстларның сәнгатьле укылышын тыңлый ала, сүзлек диктантлары язарга мөмкин, теге яки бу теманың өйрәнелеш дәрәҗәсен аңлау максатыннан, тест-

лар эшләп карау мөмкинчелеге бар. Дәрестә үткәрелә торган ял минутлары өчен төрле кызыклы физик күнегүләр электрон дәреслекләрнең кыйммәтен тагын да арттыра.

Әдәбият:

1. Сәгъдиева Р.К., Гарәпшина Р.М., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 6 нчы с-ф. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2015. – 191 б.

2. Сәгъдиева Р.К., Кадирова Э.Х. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 9 нчы с-ф. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2015. – 143 б.

3. Сәгъдиева Р.К., Харисова Г.Ф., Сабирҗанова Л.К., Нуриева М.Ә. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7 нче с-ф. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2015. – 215 б.

4. Сәгъдиева Р.К., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2015. – 223 б.

5. Шәмсетдинова Р.Р., Һадиева Г.К., Һадиева Г.В. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5 нче с-ф. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2015. – 175 б.